Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № №XXVII-1**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 17 гыйнвары

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Х. Хәбибуллинның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 маддәсендәге 10 өлешенең 2 пункты, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 маддәсендәге 6 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 51 маддәсендәге 1 өлешенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Хәбибуллин Рашат Хәбри улының шәхси гаризасы буенча отставкасын кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Хәбибуллин Рашат Хәбри улының вәкаләтләре вакытыннан алда 2018 елның 17 гыйнварыннан туктатылган дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев